ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

22.01.2026 № 67

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар тарафыннан (түләүле яисә түләүсез шартларда) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2018 елның 28 ноябрендәге 2589 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар тарафыннан (түләүле яисә түләүсез шартларда) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2018 елның 28 ноябрендәге 2589 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар тарафыннан (түләүле яисә түләүсез шартларда) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентының 2.5 пунктында

«- никах турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән граждан никахта торса);» сүзләрен

«-чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе» сүзләренә алмаштырырга ;

1.2. Административ регламентның 2.9 пунктындагы икенче баганаыны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Баш тарту өчен нигезләр:

опекуннар (попечительләр) итеп билгеләнә яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында уңай бәяләмәләр гражданнарның түбәндәге категорияләренә бирелә алмый:

1) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән затлар;

2) шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан, яла ягудан һәм хурлаудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай җәмәгать иминлегенә, дөнья һәм кешелек куркынычсызлыгына каршы җинаятьләр өчен хөкем ителүе булган яисә элек хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар яисә элек дучар булган затлар (җинаять эзәрлекләве реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылган затлардан тыш);

3) авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителгән затлар;

4) Гаилә кодексының 127 статьясындагы 6 пункты белән билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (балаларның якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы булып торучы яисә булган һәм үзләренә карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан һәм балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәүдән читләштерелмәгән затларлардан тыш);

5) бер җенестәге затлар арасында төзелгән берлектә торучы затлар, мондый өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә өйләнешү дип танылган һәм теркәлгән, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булып торучы һәм никахта тормаучы затлар;

6) җенесен үзгәрткән затлар, шулай ук җенесен алмаштыруга, шул исәптән кешедә башка җенеснең беренчел һәм (яисә) икенчел җенес билгеләрен булдыруга юнәлдерелгән дару препаратларын куллануны кертеп, медицина катнашы белән җенесен алыштыру рөхсәт ителгән дәүләтләр гражданнары булган затлар һәм шәхесне таныклаучы документларга әлеге гражданнарның җенесенә кагылышлы үзгәрешләрне медицина катнашыннан башка кертү, һәм күрсәтелгән дәүләтләрдә даими яшәү урыны булган гражданлыгы булмаган затлар.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү хокукы билгеләнә торган тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документлар, тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр тапшыру.

Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр юк.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00F37EFECAF99452BE23BE7D3B3145FA83
Владелец: Хакимуллин Рамиль Фатихович
Действителен с 01.11.2024 до 25.01.2026


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН